ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм $32^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

## 1 статья

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 86 (I өлеш), № 92 (I өлеш), № 95 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш), № 56 (I өлеш); 2025, № 1 (I өлеш), № 18 (I өлеш), № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 32 статьяның 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Өч һәм аннан күбрәк баласы булган, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге яисә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә даими яшәүче, әлеге Кодексның $32^1$ статьясындагы 11 пунктында каралган индивидуаль торак төзелешен гамәлгә ашыру, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару (йорт янындагы җир кишәрлеге), үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү өчен җир кишәрлеге алу хокукы булган гражданнар исемлекләренә кертелгән гражданнарга, аларның ризалыгы белән, җир кишәрлеге урынына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән күләмдә һәм тәртиптә акчалата түләү бирелә.»;

2) $32^1$ статьяның 15 пунктына:

а) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пунктча өстәргә:

«$1^1$) гражданнар тарафыннан әлеге Кодексның 32 статьясындагы 3 пунктының җиденче абзацы нигезендә җир кишәрлеге урынына акчалата түләү алынса;»;

б) уникенче абзацны унөченче абзац дип санарга һәм анда «Гражданнарны» сүзен «$15^1$. Гражданнарны» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2025 ел, 03 октябрь
№ 65-ТРЗ